**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 3 апрель № 208

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сууткәрү-канализация хуҗалыгы оешмаларының канализация системаларына агынты суларны һәм пычратучы матдәләрне ташлаган өчен түләү алу тәртибе турында» 2004 ел, 30 декабрь, 589 нчы карары белән расланган Сууткәрү-канализация хуҗалыгы оешмаларының канализация системаларына агынты суларны һәм пычратучы матдәләрне ташлаган өчен түләү алу тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сууткәрү-канализация хуҗалыгы оешмаларының канализация системаларына агынты суларны һәм пычратучы матдәләрне ташлаган өчен түләү алу тәртибе турында» 2004 ел, 30 декабрь, 589 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 9 март, 85 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Сууткәрү-канализация хуҗалыгы оешмаларының канализация системаларына агынты суларны һәм пычратучы матдәләрне ташлаган өчен түләү алу тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктта «лимитлары» сүзен «нормативлары» сүзенә алмаштырырга;

3 нче пунктта:

беренче абзацта «агынты суларны агызуга лимитны» сүзләрен «су таратуның билгеләнгән нормативларын» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «лимиттан тыш» сүзләрен «нормативтан тыш» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «лимиттан тыш» сүзләрен «нормативтан тыш» сүзләренә алмаштырырга;

5 нче пунктта:

беренче абзацны төшереп калдырырга;

өченче абзацта «билгеләнгән нормативлардан тыш пычратучы матдәләр массасына түләү нормативлары, ләкин билгеләнгән лимитлар чикләрендә, экологик факторны исәпкә алучы коэффициентка һәм индексация коэффициентына» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләү ставкалары һәм өстәмә коэффициентлар турында» 2016 ел, 13 сентябрь, 913 нче карары белән расланган әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләү ставкалары, билгеләнгән нормативлардан тыш пычратучы матдәләр массасына 25 арттыру коэффициентын исәпкә алып» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«канализация системасына пычратучы матдәләрне ташлаган өчен түләү әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләү ставкаларыннан чыгып хисаплана.»;

8 нче пунктта «нормативларына» сүзен «ставкаларына» сүзенә алмаштырырга;

9 нчы пунктта «квартал саен кварталдан соң килә торган айның 15енә кадәр оешмалар счетына» сүзләрен «оешмаларга түләү өчен счет чыгарылган көннән соң 10 көн эчендә» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2017\208.docx